| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.06.2025 ел Алабуга шәһәре № 438

Алабуга муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2024 елның 11 декабрендәге 399 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Алабуга муниципаль районындагы бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 статьясына таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2024 елның 11 декабрендәге 399 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

*1 нче өлештә:*

1 пунктта «3 627 567,7» саннарын «3 671 780,9» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «4 452 426,6» саннарын «4 694 528,0» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «824 858,9» саннарын «1 022 747,1» саннарына алмаштырырга;

*3 өлештә:*

1 нче кушымтаның «2025 елга район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаның «2025 елга район бюджетының фаразлана торган керемнәре күләме» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

3) 4 статьяда:

3 нче кушымтаның «2025 елга район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 1 нче таблицасындагы 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

4 нче кушымтаның «2025 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары

һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 1 нче таблицасындагы 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымтаның «2025 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү» 1 нче таблицасындагы 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

4 пунктта 2025 елга район бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме «94 527,4» санын «100 798,1» санына алмаштырырга.

5 пунктта:

-- бюджет чыгымнары классификациясенең «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» бүлекчәсе буенча:

1) 2025 елга «138 663,1» санын «112 749,6» санына алмаштырырга.

- бюджет чыгымнары классификациясенең «Мәдәният һәм кинематография» бүлегенең «Мәдәният өлкәсендә башка мәсьәләләр» бүлекчәсе буенча:

1) 2025 елга «13 875,2» санын «7 524,8» санына алмаштырырга.

5) «2025 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләме» 16 статьясында 10 нчы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү һәм туризм мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

Рәис урынбасары Р.З. Шиһапов